**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Югары Сәрдә авыл җирлеге башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**25 декабрь 2024 ел.** **№ 13**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 17 августындагы 17 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Башкарма комитетының резерв фондыннан акча тоту тәртибе турында нигезләмәгә" үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясындагы 7 өлеше нигезендә карар бирәм:

1. Югары Сәрдә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 17 августындагы 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту тәртибе турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле яңа пункт өстәргә:
“23.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен файдалану турында хисап тиешле бюджетның үтәлеше турындагы еллык хисапка кушымта итеп бирелә”.

2. Әлеге карарны http//pravo.tatarstan.ru веб - адресы буенча «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http//atnya.tatar.ru веб- адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әтнә
муниципаль районы Югары Сәрдә
авыл җирлеге башлыгы: Хөснетдинов Р.Р.